# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# К А Р А Р

21.11.2016 № 109

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

«2017 елда Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- Яңасала авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш салу

торак пунктларда:

Яңасала авылы, Яшьләр ур., 1 -9

дер. Каенсар авылы, Урта ур., 1-26

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә”.

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 355 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-341, бу 96,06 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 321 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 94,13 % тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 20 кеше тавыш бирде, бу 5,87 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. «2017 елда Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- Яңасала авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш салу

торак пунктларда:

Яңасала авылы, Яшьләр ур., 1 -9

дер. Каенсар авылы, Урта ур., 1-26

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә” соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева